РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«5» октября 2020 ел г. Альметьевск № 1465

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «2020-2022 елларга Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында муниципаль хезмәтне үстерүнең муниципаль программасын раслау турында» 2019 елның 19 ноябрендәге 2006 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Төзәтүләр тәртибендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «2020-2022 елларга Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында муниципаль хезмәтне үстерүнең муниципаль программасын раслау турында» 2019 елның 19 ноябрендәге 2006 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтада:

программа паспортында:

8 юлны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Еллар һәм чыганаклар буенча программаны финанслау күләме, | - Муниципаль Программаны финанслауның гомуми күләме Әлмәт муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән 0,00 сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>2020 елда - 0,00 сум;<br>2021 елда - 0,00 сум:<br>2022 елда - 0,00 сум. |

Программаның 3 бүлегендә:

беренче абзацта:

«1 874 800,00» санын «0,00» санына алмаштырырга;

«2020 елда - 1 874 800,00 сум» сүзләрен «2020 елда - 0,00 сум» сүзләренә алмаштырырга;

«2020-2022 елларга Әлмәт муниципаль районында муниципаль хезмәт үсеше муниципаль программасын төп чаралар һәм финанс белән тәэмин итү» кушымтасының 4.1. юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| №№ п/п | Чараның исеме | Башкару сроклары | Финанс чаралары (сум) | | | Финанслау чыганагы | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары | Җаваплы башкаручылар | Чараларны гамәлгә ашыруның көтелә торган нәтиҗәләре |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2020 | 2021 | 2022 | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 4.1. | Муниципаль хезмәткәрләрне һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затларны һөнәри яңадан әзерләүне, стажировкаларны, квалификацияләрен арттыруны оештыру | 2020-2022 еллар | 0,0 | 0,0 | 0,0 | җирле бюджет акчалары | тиешле елда квалификация күтәрүне, һөнәри яңадан әзерләүне, стажировканы узган муниципаль хезмәткәрләрнең һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның өлеше (2020-10%, 2021-10%, 2022-10%) | Районның башкарма комитеты | муниципаль хезмәткәрләрнең һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның һөнәри эшчәнлекнең яңа төрен үтәү өчен өстәмә белем, күнекмәләр алу, аларны яңа икътисадый һәм социаль шартларга яраклаштыру |

«2020-2022 елларга Әлмәт муниципаль районында муниципаль хезмәт үсеше муниципаль программасын төп чаралар һәм финанс белән тәэмин итү» кушымтасының 6.3 юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| №№ п/п | Чараның исеме | Башкару сроклары | Финанс чаралары (сум) | | | Финанслау чыганагы | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары | Җаваплы башкаручылар | Чараларны гамәлгә ашыруның көтелә торган нәтиҗәләре |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2020 | 2021 | 2022 | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| 6.3. | Уку тренинглары, тестлар үткәрү | 2020-2022 еллар | 0,0 | 0,0 | 0,0 | җирле бюджет акчалары | тиешле елда аттестация узган муниципаль хезмәткәрләр өлеше (2020 – 100%, 2021 – 100%, 2022 – 100%) | Районның башкарма комитеты | коллективта мораль-психологик климатны оптимальләштерү, коллективның бердәмлеге һәм берләшүе атмосферасын булдыру, персонал белән идарә итү нигезләрен формалаштыру |

2. Район Башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту аппарат җитәкчесе Р.Е. Әфләтуновага йөкләргә.

Район
башкарма комитеты җитәкчесе М.Н. Гирфанов